КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 8 апрель г.Казань № 338

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле турында» 2019 ел, 25 октябрь, 956 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле турында» 2019 ел, 25 октябрь, 956 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 сентябрь, 859 нчы, 2021 ел, 19 июль, 590 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле тәртибенә, 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Вәкаләтле органның халык алдында төзелгән максатларын һәм бурычларын үтәү

5.1. Халык алдында төзелгән максатлар һәм бурычлар вәкаләтле орган тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булып тора һәм тармак стратегияләрен һәм башка программа документларын актуальләштергәндә исәпкә алына.

5.2. Халык алдында төзелгән максатларның һәм бурычларның үтәлешенә җәмәгать контролен тәэмин итү максатларында вәкаләтле орган:

I, II һәм III квартал йомгаклары буенча хисап кварталыннан соң килүче айның 20 сенә кадәр әлеге Тәртипнең 1.5 пункты нигезендә күрсәтелгән максатларны һәм бурычларны гамәлгә ашыру турында мәгълүматны үзенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә, шулай ук «Дәүләт хакимияте башкарма органнары максатларын һәм бурычларын ачыктан-ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешен җәмәгать контроле» бүлегенә урнаштыру өчен техник операторга тапшыра;

беренче яртыеллык нәтиҗәләре буенча аларның үтәлеше турында агымдагы елның 1 августына кадәр иҗтимагый совет утырышында хәбәр итә;

ел йомгаклары буенча хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр әлеге Тәртипнең 1.5 пункты нигезендә вәкаләтле органның халык алдында төзелгән максатларын һәм бурычларын башкару турында хисап проектын бастырып чыгаруны тәэмин итә, аны «Дәүләт хакимияте башкарма органнары максатларын һәм бурычларын ачыктан-ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешен иҗтимагый контроль» бүлегенә урнаштыру өчен техник операторга тапшыра, шулай ук вәкаләтле органның халык алдында төзелгән максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен җәмәгать тикшерүен үткәрү турында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына тәкъдим кертә.

5.3. Вәкаләтле органның халык алдында төзелгән максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен иҗтимагый фикер алышу Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының халык алдында төзелгән максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыру тәртибенә ярашлы рәвештә уздырыла.

5.4. Җәмәгать фикер алышуы барышында килгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кысаларында кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, хисап чорыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр, вәкаләтле органның халык алдында төзелгән максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру турында хисап һәм җәмәгать фикер алышуы нәтиҗәләре әлеге Тәртипнең 1.5 пункты нигезендә урнаштырыла.

5.5. Техник оператор хисап чорыннан соң килүче елның 15 мартына кадәр кулланучыларга хезмәт күрсәтүләр порталының шәхси кабинетларында урнаштырылган хәбәрнамәләр көйләүгечләре нигезендә хезмәт күрсәтүләр порталының «Дәүләт хакимияте башкарма органнары максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле» бүлегендә ел йомгаклары буенча ачык формалаштырылган максатларны һәм бурычларны тормышка ашыру турындагы хисапларны бастырып чыгару турында хәбәрнамәләр җибәрүне тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин